# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлегенең Сөлек авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**18 ноябрь 2020 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 18 ноябрендә 13.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 350 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:
- Сөлек авылында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
-МТЗ-320,4 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт өчен түләү);
- бәйрәмнәрне үткәрү өчен бүләкләр (Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май);
- Сөлек авылында Мәктәп урамындагы юлларга вак таш җәю (таш ташу) ремонт;
- Сөлек авылында зират территориясен эйлэндеру очен материаллар сатып алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 135 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 85 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 85катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлегенең Сөлек авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.
2. «2021 елда 350 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:
- Сөлек авылында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
-МТЗ-320,4 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт өчен түләү);
- бәйрәмнәрне үткәрү өчен бүләкләр (Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май);
- Сөлек авылында Мәктәп урамындагы юлларга вак таш җәю (таш ташу) ремонт;
- Сөлек авылында зират территориясен эйлэндеру очен материаллар сатып алу

кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Шәрләрәмә авыл җирлегенең Сөлек мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Н.Н.Хуҗина